**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 6 август № 536

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче, 2016 ел, 20 февраль, 103 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.19 пункт үз көчен югалтуын танырга,;

4.1.22 пунктка «һәм аннан мәгълүматлар бирү» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.49$^{1}$ һәм 4.1.49$^{2}$ пунктларны өстәргә:

«4.1.49$^{1}$. Террорчылыкка каршы тору буенча чараларны тормышка ашырганда укулар үткәрүдә катнаша.

4.1.49$^{2}$. Министрлыкка беркетелгән объектларны (территорияләрне) террорчылыктан саклауга карата таләпләрне үтәүне оештыра һәм тәэмин итә.»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 пункт өстәргә:

«5.9. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Түбәндәгеләрнең үз көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре реестры турында» 2010 ел, 12 апрель, 255 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 19 август, 599 нчы карарының 9 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков